**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне, дини һәм милли җирлектәге низагларны алдан кисәтүне комплекслы мониторинглау системасы турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

Федераль башкарма хакимият органнары структурасында үзгәрешләр белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне, дини һәм милли җирлектәге низагларны алдан кисәтүне комплекслы мониторинглау системасы турында» 2015 елның 25 апрелендәге ПУ-414 номерлы (Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 14 ноябрендәге ПУ-1095 номерлы һәм 2016 елның 27 февралендәге ПУ-215 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) Указына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 5 пунктта «Федераль миграция хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе,» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне, дини һәм милли җирлектәге низагларны алдан кисәтүне комплекслы мониторинглау системасы турында нигезләмәнең 8 пункты унынчы абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2016 ел, 29 сентябрь
№ ПУ-880